| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ГОРОДА БУИНСКА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БУА ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«02» сентябрь 2025ел №36

Буа шәһәре

«Хайваннарны хуҗаларыннан башка кайтару тыелган урыннарны билгеләү һәм хайваннарны хуҗаларыннан башка элекке яшәү урыннарына хуҗаларыннан башка кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеген билгеләү турында»

«Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы 6.1. өлеше, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14.1 статьясы нигезендә, 2012 елның 13 гыйнварындагы 9-ТРЗ номерлы «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннар белән эш итү өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына таянып, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының "Буа шәһәре" муниципаль берәмлеге Уставы белән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Хайваннарны хуҗаларыннан башка кайтару тыела торган урыннар исемлеген 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Хайваннарны хуҗаларыннан башка элекке яшәү урыннарына хуҗаларыннан башка кайтару турынд карар кабул итәргә вәкаләтле затлар исемлеген 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Карар билгеләнгән тәртиптә басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында басылып чыгарга (http://pravo.tatarstan.ru), Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Буа муниципаль районының рәсми сайтында ( https://buinsk.tatarstan.ru/) урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Буа шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Сафин

Буа муниципаль районы Башкарма комитетының
02.09.2025 елдан 36 номерлы  карарына
1 нче кушымта

Хайваннарны хуҗаларыннан башка кайтару
тыела торган урыннар исемлеге

- Гомуми файдаланудагы территорияләр (шул исәптән мәйданнар, урамнар, юллар, парклар, скверлар һәм башка территорияләр тоткарлыксыз файдалана затларның чикләнмәгән даирәсе);
- күпфатирлы йортлар янындагы территорияләр;
- балалар өчен уен һәм балалар өчен спорт мәйданчыклары;
- актив спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен каралган мәйданчыклар;
- массакүләм чаралар уздыру мәйданчыклары;
- балалар, мәгариф һәм дәвалау учреждениеләре территорияләре;
- мәдәният объектларына якын территорияләр;
- җәмәгать туклануы оешмалары, кибетләр янындагы территорияләр.

Буа муниципаль районы Башкарма комитетының
02.09.2025 елдан 36 номерлы карарына
2 нче кушымта

Хайваннарны хуҗаларыннан башка элекке яшәү урыннарына хуҗаларыннан башка кайтару турынд карар кабул итәргә вәкаләтле затлар исемлеге

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе